**ГЛАВА КУРКАЧИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422730, Республика Татарстан, Высокогорский район, пос.ж.д.рзд. Куркачи, ул.Гагарина, 7

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КОРКАЧЫК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**
422730, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Коркачык тимер юл разъезды поселогы, Гагарин ур, 7

Тел./факс: +7(84365) 71-2-15, e-mail: Kurk.Vsg@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**«10» октябрь 2022 ел** **№ 3**

**Гражданнарның үзара салымы чараларыннан файдалану турында Биектау муниципаль районы Коркачык авыл җирлеге Коркачык тимер юл разъезды поселогында гражданнар җыенын билгеләү**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Коркачы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы, «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Коркачы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы « Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Коркачык авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы

**КАРАР ИТТЕ:**

***1.*** Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Коркачык авыл җирлеге Коркачык тимер юл разъезды поселогында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыеның беренче этапын 2022 елның 21 октяберенә 17 сәгать 00 минутка билгеләргә.

***2.*** Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Коркачык авыл җирлеге Коркачык тимер юл разъезды поселогында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыеның икенче этапын 2022 елның 28 октяберенә 17 сәгать 00 минутка билгеләргә.

***3. Коркачык тимер юл разъезды бистәсендә яшәүчеләр исемлеген гражданнар җыенын үткәрү өчен территориаль билге буенча бүләргә:***
***1 этап: Заречная урамы, Королев урамы, Сәйдәшев урамы, Урман урамы, Тукай урамы, Төзүчеләр урамы, Гагарин урамы.***
***2 этап: Горький урамы, Мирная урамы, Завод урамы, Яшьләр урамы, Трудовая урамы, Набережная урамы, Энергетиклар урамы.***

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Коркачык авыл җирлеге Коркачык тимер юл разъезды бистәсе территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү турында килешәсезме һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтелгән түбәндәге эшләрне башкару: БВС һәйкәле төзү, балалар мәйданчыгы, трактор хезмәте күрсәтү, вак таш сатып алу.

« ЭЙЕ»                                        «ЮК».

5. Әлеге карарны мәгълүмати стендларга һәм җирлекнең рәсми сайтына кабул ителгәннән соң 3 көн эчендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

6. Әлеге карар аның басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Авыл җирлеге башлыгы                                        Р.Ф. Салихҗанов